ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.04.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 961**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычы арту бәйле, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2022 елның 06 апрелендәге 319 номерлы карары һәм «2022 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында» 2022 елның 21 февралендәге 148 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022елның 25 нче апреленнән 15 нче маена кадәр Зеленодольск муниципаль районы территориясендә (алга таба –текст буенча ЗМР) янгынга каршы махсус режим билгеләргә.
2. Янгынга каршы махсус режим үз көчендә булган чорда түбәндәгеләрне тыярга:

– учаклар кабызу, каты көнкүреш калдыкларын, коры үләнне һәм чүп-чарны яндыру;

– мангаллардан һәм башка җайланмалардан гайре җәмәгать туклануы объектлары (рестораннар, кафе, барлар һ. б.), урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктларда гражданнар бакчачылык яки яшелчәчелек (алга таба – бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте), балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман массивлары белән чиктәш икътисад объектлары территорияләрендә урнашкан.;ризык әзерләү өчен махсус янмый торган савытларда (мангалларда, жаровняларда һ. б.), ризыкны җылыту өчен башка җайланмаларда ачык ут куллану;

– урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар, гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре, урман кишәрлекләре белән чиктәш балалар сәламәтләндерү лагерьлары, икътисад объектлары, сәламәтләндерү оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман паркы зоналарында, торфлы кишәрлекләрдә һәм урман массивлары белән чиктәш территорияләрдә ачык утта (учаклар, мангаллар) ризык пешерү, 1 – 3 класстагы куркынычлы пиротехник эшләнмәләр куллану.

– биеклеккә ачык ут ярдәмендә корылма эчендәге һаваны җылытуга нигезләнгән, яна торган материаллардан ясалган, идарә ителми торган эшләнмәләрне

җибәрүне

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына, «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесе Н.Н.Минһаҗевка (шәһәр буенча), янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда (аерым кагылганда), милек формасына карамастан ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә):

– ведомство буйсынуындагы объектларда территорияне коры үлән һәм чүптән чистарту буенча чаралар күрергә;

– баланста булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

– янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда ведомство карамагындагы территорияләрдә янгын куркынычы янаган эшләр үткәрүне чикләргә.

- урман янгыннары куркынычы һәм башка ландшафт (табигый) янгыннар янаган торак пунктларда вакытлыча янгынга каршы постлар булдыру;

– авыл җирлекләре администрацияләре, якын-тирә урманчылыклар, ЗМР буенча ГХД, Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге, Административ-техник инспекция хезмәткәрләре арасыннан торак пунктларны, урман массивларын, торак пунктларга якын-тирә территорияләрне, урман-парк зоналарын һәм бакчачылык җәмгыятьләрен карап чыгу өчен профилактик төркемнәр эшен оештырырга;

– торак пунктларны һәм икътисад объектларын табигать (урман) янгыннарыннан саклау өчен минераллаштырылган полосалар булдыру, территорияләрне коры үлән үсемлекләреннән, ауган агачлардан, чүп-чардан һәм башка ягулык материалларыннан, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә хуҗасыз һәм озак вакыт файдаланылмый торган җир участокларыннан чистарту эшләрен дәвам итәргә;

– янгын автомобильләре белән су алу өчен табигый һәм ясалма сулыкларны һәм керү юлларын төзек хәлдә тотуны тәэмин итәргә;

– халыкка вакытында хәбәр итүне тәэмин итәргә (барлык мөмкин булган чаралар (РСУ, сиреналар, экстрен хезмәтләр техникасы, мәчетләр, подвалларны карап чыгу һ.б.).

– урман (табигый) янгыннары килеп чыккан очракта, халыкны куркынычсыз районнарга вакытында эвакуацияләүне тәэмин итәргә);

– кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының янгын куркынычы янаган чорда эшләүгә әзерлеген тикшерергә;

– эвакуацияләнгән халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итү планнарын эшләргә;

– язгы-җәйге янгын куркынычы янаган чорда халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау буенча эш алып барырга, бу юнәлештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итәргә.

4. Авыл җирлекләре Башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

– җирлекләрдә торак пунктларының янгыннан сакланышын ныгытуга юнәлдерелгән, шул исәптән чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү буенча хокукый актлар кабул итәргә;

– урман янгыннары хәле катлауланган чорда ирекле янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын төзергә, шулай ук су сиптерү һәм янгын сүндерү өчен башка җайлаштырылган техниканы җәлеп итү планнарын төзергә.

5. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ДЯКХ ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отрядыны башлыгы торак пунктларны, икътисад объектларын табигый янгыннардан саклауны контрольгә алырга, шулай ук табигый янгын чыганакларын үз вакытында ачыклау һәм аларны табу көнендә бетерү эшен оештырырга тәкъдим итәргә;

– космик мониторинг чаралары тарафыннан табылган янгыннар (термик нокталар) турында сигналларга вакытында җавап бирүне тәэмин итәргә;
– Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең НД һәм ПР бүлеге белән берлектә массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге проблемалы мәсьәләләрне яктыртырга, шулай ук халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итәргә.

6. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы Р. Р. Ардыхановка янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда тәкъдим итәргә:
– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ДЯКХ ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отряды белән берлектә превентив янгын-профилактик чаралар комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;
– 2022 елның 1 июненә кадәр торак пунктларның, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренең, урман кишәрлекләре белән чиктәш гражданнарның массакүләм ял итү урыннарында, балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча планлы (рейд) тикшерүләр үткәрү, территорияләрне тикшерү;
– урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларга карата күзәтчелек буенча чаралар үткәрергә.

7. Зеленодольск МР территориясендә урнашкан урманчылык җитәкчеләренә (урманчыларга), «Идел-Кама дәүләт тыюлыгы» ФДБУ директорына, янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
– 2022 елның 25 апреленнән 15 маена кадәр янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү буенча гражданнарның күпләп ял итү урыннарына һәм урманнарга патрульлек итүне;
– урман янгыннары белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда һәм барлыкка килгәндә халыкка гамәлләр алгоритмы буенча массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерүне оештыруны;
– урман массивларында һәм алар янында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгынга каршы техника белән су алу өчен мәйданнарны уңайландыруны дәвам итәргә;урман янгыннарын башлангыч стадиядә ачыклауга, локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән оператив чаралар күрүне тәэмин итүне;
– урман янгыннарын сүндерү өчен янгынга каршы техниканы, транспорт чараларын, шулай ук урман янгыннарын сүндерү планы нигезендә юридик затларны һәм гражданнарны җәлеп итүне;
– ЗМР шәһәр (авыл) җирлекләре Башлыкларына торак пунктларның урман массивларына тоташкан урыннарда чик буенча минераллаштырылган полосаларны урнаштыруда булышлык күрсәтүне;
– урман фондында эшләр башкаручы ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм оешмаларның урман янгыннарын сүндерүгә көчләрен һәм чараларын даими әзерлектә тотуны;
– урман янгыннарын сүндерү формированиеләрен шәхси состав белән билгеләнгән нормативларга туры китереп комплектлаштырырга, шәхси составка өйрәтүләр оештыруны;
– махсус урман янгыннарын сүндерү техникасын һәм җиһазларны техник яктан төзек хәлгә китерүне.

8 «ЗМР БК төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары И.А. Мәхмүтовка, юл оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда һәм янгын куркынычы сезоны дәвамында федераль, республика һәм муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләреннән чүп-чардан системалы рәвештә чистартуны тәэмин итәргә.

– 9.Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зеленодольск авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Т.Г. Җиһаншинга янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм алар янәшәсендәге урман массивларында язгы кыр эшләрен үткәргәндә авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын оештыруны тәкъдим итәргә.

10. «Зеленый Дол тимер юл станциясе башлыгы Е.В.Марунинга, «Зеленый Дол» тимер юл вокзалы башлыгы Е.В. Габбазовка тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларда янгынга каршы профилактик чаралар комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларда янгын чыгу очраклары турында оператив мәгълүматны 5-93-07, 6-77-11, 6-77-12. телефон номеры аша ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отряды диспетчерлык бүлегенә тапшырырга киңәш итәргә.

11. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Зеленодольск муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы полиция полковнигы А.Р. Ханбиковка урман-парк зоналарына һәм гражданнарның күпләп ял итү урыннарына патрульлек итү чорында урманчылыклар җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре Башлыкларына законнарда каралган тәртиптә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

12.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 997 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

13.Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда һәм янгын куркынычы янаган чорда ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (Чибрикова Р.Н.):

- әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы ЗМР рәсми сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә;

-язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгын пропагандалый торган видео-һәм аудиороликлар эшләргә һәм аларны Зеленый Дол» телеканалында трансляцияләүне оештырырга;

-басма массакүләм мәгълүмат чараларында ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ДЯКХ ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отряды белән берлектә халык өчен куркынычсыз тәртип кагыйдәләрен бастыру өчен «ГТХМ кисәтә» профилактик рубрикасын оештырырга;

-янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен гражданнарга, вазыйфаи һәм юридик затларга административ җаваплылык турында мәгълүмат урнаштыруны оештырырга.

14.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкчесе И.Р. Ганиев